КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 13 июль г.Казань № 574

2019 елда цифрлы телевидение тапшыруы сигналын кабул итү өчен цифрлы телевидение приставкасы һәм (яки) телевидение антеннасы сатып алу чыгымнарына компенсация бирү турында

Татарстан Республикасында цифрлы телевидение тапшыруына күчкәндә гражданнарның социаль якланмаган категорияләренә адреслы ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елда гражданнарның аерым категорияләренә цифрлы телевидение тапшыруы сигналын кабул итү өчен кирәк булган түбәндәге әйберләрне сатып алу чыгымнарына бер тапкыр түләнә торган компенсацияләр бирүне билгеләргә:

цифрлы телевидение приставкасын – факттагы кыйммәте, әмма иң күбе 1 мең сум күләмендә;

телевидение антеннасын – факттагы кыйммәте, әмма иң күбе 1 мең сум күләмендә;

2. Бу карарга теркәлгән 2019 елда гражданнарның аерым категорияләренә цифрлы телевидение тапшыруы сигналын кабул итү өчен цифрлы телевидение приставкасы һәм (яки) телевидение антеннасы сатып алу чыгымнарына бер тапкыр түләнә торган компенсацияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.

3. Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына цифрлы телевидение тапшыруы сигналын кабул итү өчен цифрлы телевидение приставкасы һәм (яки) телевидение антеннасы сатып алу чыгымнарына бер тапкыр түләнә торган компенсацияләр бирү өчен кирәкле гамәли программа продуктын эшләүне тәэмин итәргә.

4. Цифрлы телевидение тапшыруы сигналын кабул итү өчен цифрлы телевидение приставкасы һәм (яки) телевидение антеннасы сатып алу чыгымнарына

бер тапкыр бирелә торган компенсацияләр түләү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында әлеге максатларга күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

5. Цифрлы телевидение тапшыруы сигналын кабул итү өчен цифрлы телевидение приставкасы һәм (яки) телевидение антеннасы сатып алу чыгымнарына бер тапкыр түләнә торган компенсацияләр бирү турындагы мәгълүмат Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла. Әлеге мәгълүматны Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру (алу) «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 13 июль, 574 нче
карары белән расланды

# 2019 елда гражданнарның аерым категорияләренә цифрлы телевидение тапшыруы сигналын кабул итү өчен цифрлы телевидение приставкасы һәм (яки) телевидение антеннасы сатып алу чыгымнарына бер тапкыр түләнә торган компенсацияләр бирү тәртибе турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип 2019 елда гражданнарның түбәндәге категорияләренә цифрлы телевидение тапшыруы сигналын кабул итү өчен цифрлы телевидение приставкасы һәм (яки) телевидение антеннасы сатып алу чыгымнарына бер тапкыр түләнә торган компенсацияләр (алга таба – компенсацияләр) бирү тәртибен һәм шартларын билгели:

18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк балалары булган (тәрбиягә алган балаларны кертеп), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән билгеләнгән Тәртиптә балага ай саен бирелә торган пособие алып баручы гаиләләргә;

инвалид балалары булган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән билгеләнгән Тәртиптә балага ай саен бирелә торган пособие алып баручы гаиләләргә;

70 яше тулган һәм аннан да өлкәнрәк булган, җан башына уртача кереме 20 мең сумнан артыграк булмаган ялгыз яшәүче пенсионерларга (пенсионерлары булган гаиләләргә);

җан башына уртача кереме 20 мең сумнан артыграк булмаган ялгыз яшәүче инвалидларга (инвалидлары булган гаиләләргә).

1.2. Компенсацияләр бу Нигезләмәнең 1.1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнар категорияләренә (алга таба – гаилә (ялгыз яшәүче граждан)) бер тапкыр бирелә.

1.3. Компенсацияләр бирү максатларында гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) җан башына уртача кереме «Гаиләне һәм ялгыз яшәүче гражданны аз керемлеләр дип тану һәм аларга дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен аларның керемнәрен исәпкә алу һәм җан башына уртача керемен исәпләп чыгару тәртибе турында» 2003 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 5 – 12, 14 статьялары белән билгеләнгән кагыйдәләр буенча, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гаиләгә һәм ялгыз яшәүче гражданга дәүләт социаль ярдәме күрсәтү

өчен аларның җан башына уртача керемен исәпләп чыгарганда исәпкә алына торган керемнәр төрләре исемлеге турында» 2003 елның 20 августындагы 512 номерлы карары белән расланган гаиләгә һәм ялгыз яшәүче гражданга дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен аларның җан башына уртача керемен исәпләп чыгарганда исәпкә алына торган керемнәр төрләре исемлегендә күрсәтелгән керемнәр төрләрен исәпкә алып исәпләп чыгарыла.

Компенсацияләр билгеләү өчен гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) җан башына уртача кереме компенсация билгеләү турында гариза биргән айга кадәр килгән соңгы өч календарь аена (алга таба – исәп-хисап чоры) билгеләнә.

Гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) әгъзалары ризалыгы булганда, компенсацияләр билгеләү гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) һәр әгъзасының Россия Федерациясе Пенсия фондында аларны билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән ай алдыннан килгән 12 айның соңгы өч аена булган керемнәре турындагы мәгълүматлар нигезендә башкарыла.

Исәп-хисап чорында гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) җан башына уртача кереме гаиләнең уртача айлык җыелма керемен йорт хуҗалыгы әгъзалары санына бүлү юлы белән исәпләп чыгарыла.

Исәп-хисап чорында гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) уртача айлык җыелма кереме гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) барлык әгъзаларының уртача айлык керемнәре суммасына тигез була.

Гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) һәр әгъзасының уртача айлык кереме аның исәп-хисап чоры эчендә алынган керемнәре суммасын бу исәп-хисап чорының әлеге керемнәрен алган айлары санына бүлү юлы белән билгеләнә.

1.4. Гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләп чыгарганда гаилә составына яшәү урыны буенча бер адреста бергәләп яшәүче гражданнар кертелә.

Гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) җан башына уртача керемен исәпләп чыгарганда, аерым яки бергәләп яшәвенә карамастан, ир белән хатынның һәм аларның балигъ булмаган балаларының керемнәре исәпкә алына.

1.5. Компенсацияләр бирү турындагы карарлар аларны алуга хокукы булган гражданнарның яшәү урыны буенча «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлекләрендә (алга таба – Үзәк бүлеге) кабул ителә.

## II. Компенсация билгеләү тәртибе

2.1. Компенсация билгеләү өчен гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) бер әгъзасы (алга таба – алучы), алучының законлы вәкиле яки алучы тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә кәгазе нигезендә вәкаләт бирелгән зат (алга таба – гариза бирүче), 2019 елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча, яшәү урыны буенча Үзәк бүлегенә түбәндәге документларны тапшыра:

алучының банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счеты реквизитлары күрсәтелгән компенсация билгеләү турында гариза;

компенсация билгеләү турында гариза бирү аена кадәр килгән соңгы өч календарь ае өчен алучының һәм аның гаилә әгъзаларының керемнәрен раслый торган документлар – бу Нигезләмәнең 1.1 нче пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән алучыларга компенсация билгеләнгәндә;

цифрлы телевидение тапшыруы сигналын кабул итү өчен сатып алынган цифрлы телевидение приставкасына һәм (яки) телевидение антеннасына түләүне раслый торган документ;

ышанычлы затлар өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә кәгазе;

алучының гаилә әгъзаларыннан яки аларның законлы вәкилләреннән (ялгыз яшәүче гражданнардан башка) түбәндәгеләрне раслый торган (ирекле рәвештә язылган) документ (документлар):

аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы булу;

шәхси мәгълүматларны органга яки оешмага тапшырганда гариза бирүченең алар исеменнән эш итүгә вәкаләте.

Гариза бирүчеләр гариза белән мөрәҗәгать иткәндә шәхесне раслый торган документ күрсәтә.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланырга тиеш.

2.2. Үзәк бүлеге вәкаләтле оешмалардан ведомствоара соратып алулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып электрон рәвештә, алучының даими яшәү урыны буенча аның белән бергә яшәүче затлар турында мәгълүматлар ала.

2.3. Үзәк бүлегендә бу Нигезләмәнең 2.1 нче пунктында күрсәтелгән документлардагы мәгълүматлар булган очракта, гариза бирүче әлеге документларның барысын яки бер өлешен бирүдән азат ителә.

2.4. Тапшырылган документлар һәм бу Нигезләмәнең 2.1 нче һәм 2.2 нче пунктларында күрсәтелгән мәгълүматлар нигезендә Үзәк бүлеге компенсация билгеләү турындагы гаризаны теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче 10 көн эчендә компенсация билгеләү турында яки аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга СМС-хәбәр итеп) кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

2.5. Компенсация билгеләүдән баш тарту өчен әлеге мәгълүматлар һәм документлар җыелмасы нигезендә ачыкланган аны алырга хокук булмау нигез булып тора.

## III. Компенсацияләр бирү механизмы

3.1. Алучыларга компенсацияләр аны билгеләү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән айдан соң килә торган айның 20сенә кадәр банкта яки башка кредит оешмасында ачылган счетларга күчерү юлы белән бирелә.

## IV. Йомгаклау нигезләмәләре

4.1. Гариза бирүче үзе тапшырган мәгълүматларның дөреслеге, шулай ук аларга кертелгән документларның төп нөсхәлеге өчен җавап бирә.

4.2. Компенсация алу өчен кирәкле гариза һәм документлар (мәгълүматлар) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Электрон документлар рәвешендә бирелә торган гаризалар һәм документлар (мәгълүматлар) Россия Федерациясе законнары нигезендә электрон имза белән имзалана һәм электрон йөрткечләрне һәм (яки) гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен («Интернет» челтәрен кертеп) файдаланып тапшырыла.

4.3. Компенсация алу өчен кирәкле гаризаны һәм документларны (мәгълүматларны) электрон документлар рәвешендә тапшыру әлеге гариза бирүченең компенсация алу максатларында аның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә риза булуына тиңләштерелә.

4.4. Үзәк бүлеге тарафыннан компенсация алучыларның шәхси эшләрен формалаштыру һәм саклау гамәлгә ашырыла.

4.5. Үзәк бүлеге гаебе белән үз вакытында алынмаган компенсация чикләнмәгән вакыт эчендә түләнә.

---